ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 186 от «23» 05 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 августындагы 240 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 августындагы «Яңа редакциядә күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 240 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән гыйбарәт, һәм (яисә) яңа биналар барлыкка килүдән, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планировкасын үзгәртүдән (шул исәптән аның чикләрен һәм (яисә) урынының мәйданын үзгәртүдән) гыйбарәт. Яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә шулай ук чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәрергә мөмкин. Планлаштыруны яңадан төзү чикләр турында һәм (яисә) бина (биналар) мәйданы турында яисә төзелгән биналарның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә. »;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ / веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Х. Әгъләмов

0000012175